ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм $13^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 29 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 94 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2023, № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 12 статьяга түбәндәге эчтәлекле $6^1$ – $6^3$ пунктлар өстәргә:

«$6^1$) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан автомобиль юлларында һәм урам-юл челтәрендә юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуны теркәү өчен фотога һәм кинога төшерү, видеога яздыру функцияләре булган автомат режимда эшли торган стационар махсус техник чаралар, юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуны теркәү өчен фотога һәм кинога төшерү, видеога яздыру функцияләре булган автомат режимда эшли торган күчмә махсус техник чаралар һәм (яисә) юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуны теркәү өчен фотога һәм кинога төшерү, видеога яздыру функцияләре булган автомат режимда эшли торган мобиль махсус техник чаралар (алга таба тиешенчә – стационар теркәү чарасы, күчмә теркәү чарасы, мобиль теркәү чарасы) урнаштыру (куллану) турында карар кабул итү;

$6^2$) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан автомобиль юлларында һәм урам-юл челтәрендә урнаштырылган һәм (яисә) кулланыла торган, сүндерергә һәм (яисә) сүтеп алырга тәкъдим ителгән стационар теркәү чараларын,

күчмә теркәү чараларын һәм (яисә) мобиль теркәү чараларын сүндерү (кулланмау) турында һәм (яисә) сүтеп алу хакында карар кабул итү;

6[3]) стационар теркәү чараларын, күчмә теркәү чараларын һәм (яисә) мобиль теркәү чараларын урнаштыру (куллану) турында, сүндерү (кулланмау) хакында һәм (яисә) сүтеп алу турында карарларны Федераль законның 22[1] статьясы нигезендә килештерү;»;

2) 13[1] статьяда:

а) 4 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3) түләүле гомуми файдаланудагы региональ әһәмияттәге автомобиль юллары һәм гомуми файдаланудагы хосусый автомобиль юллары, гомуми файдаланудагы региональ әһәмияттәге автомобиль юлларының һәм гомуми файдаланудагы хосусый автомобиль юлларының түләүле участоклары буйлап транспорт чаралары узуга карата транспорт чарасы йөргән өчен түләү тәртибен үтәү өлешендә.»;

б) 5 өлешнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле «в» пунктчасы өстәргә:

«в) гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге түләүле автомобиль юллары, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының түләүле участоклары буйлап транспорт чаралары узуга карата транспорт чарасы йөргән өчен түләү тәртибен үтәү өлешендә;».

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 12 апрель
№ 17-ТРЗ